К А Р А Р № 302

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е №302

2019 елның «11» марты

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2019 елга «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча халык өчен торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 2025нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «2019 елга «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча халык өчен торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 2025нче номерлы карары преамбуласына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Россия Федерациясе Торак кодексы» сүзләреннән соң, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016-2018 елларга Торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең федераль стандартлары турында» 2016 елның 11 февралендәге 97нче номерлы карары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетында бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р.Хәйбрахманов 5-44-72